### Миләшләр

/Укучылар иҗаты/

Күзләр җиткәч җимешләр
Бетә диләр, җыелып.
Авылдагы миләшләр,
Ятә анә коелып.

Чыпчыклар чыркылдаша
Миләш өстендә биеп,
Әчесеннән курыкмыйлар
Файдасын микән белеп.

Салкын да тими шуңа,
Ашыйлар тәмен белеп.
Табигать аналары
Куйгандыр инде элеп.

Кызыл алкадай яналар
Авыл урамын бизәп.
Күзгә байлыкка өстәлгән
Менә дигән бер бизәк.

Авылым байлыгына
Сокланмый мөмкинме соң?
Кошлар кебек тугры булып
Калып та булмыймы соң?

Җылыны һәм матурны
Эзләмиләр бит читтән.
Ә кешеләр гомер буе
Никтер авылдан киткән.

Гади генә кошлар әнә
Курыкмыйлар салкыннан.
Баллы ризык эзләмичә
Авыз итә миләштән.

***Зәйнәп Нурматова,***
***XI сыйныф укучысы***



### Югары кыр

/Чал тарихта эзле без! /

“Югары кыр” – туган ягыбызның гүзәл бер почмагы. Борынгы бабаларыбызның тәүге нигезләре шушы урында булганлыктанмы, бу кырда йөрү күңелне хозурландыра, җанга сихәт бирә.

Элек заманнарда авылның җирләре югары һәм түбән кырларга бүленеп йөртелгән. Чирмешән елгасын сул ягындагы далалар –“түбән кыр“, ә уң ягтагы таулы җирләр – “югары кыр“ дип аталган. Авылның 1860 нчы елларга караган хуҗалык тасвирламасында бу кырлар түбәндәгечә билгеләп үтелгән:

*“а) Земли, лежащия на левой стороне реки Малаго Черемшана, отстоят от усадьбы на 5 верст; положение ровное, открытое, степное, в общем характер слабо покатое к руслу речки; почва лучший темно-буро-серый, глинисто-песчаный чернозем, с значительною примесью перегноя, глубиною до 17 вершков, подпочва красно-бурая глина с песком. Эти земли составляют 1-й разряд. б) Земли, лежащия на правой стороне речки М. Черемшана, отстоят от усадьбы на 3,5 версты с положением гористым, сильно покатым к руслу реки; почва бурoвато-серый, песчано-глинистый (суглинистый) чернозем, с едва заметною примесью перегноя, глубиною до 10 вершков, подпочва красная глина. Эти земли отнесены ко 2-му разряду.”*

Югары кырның кызыл балчыгы кирпеч сугар өчен яраклы санала һәм моны элеккеге бабайлар да белгәннәр. Саржинат куаклыгы турысында тауга түгәрәк рәвешендә уелып кергән чокыр кирпеч сугып яндырылган урын булараk билгеле. 1750 нче елларда хәзерге урынына күчкәнчегә кадәр безнең авыл Югары кырның аскы өлешендә урнашкан булган. Кырның калган өлешен куе урман биләп торган. 1772 нче елга караган Биләр авылы җирләрен межалау кенәгәсендә бу урман *“дровяной лес деревень Черемшанов, Студеные Ключи тож”* дип күрсәтелгән. Шул урманның истәлеге булып Югары кырның көнбатыш ягында бернчә урында әле дә дистәгә якын имән агачлары шаулап үсеп утыралар. Бу урман безнең авыл биләмәсе булганлыктан, аның агачлары хуҗалык кирәге өчен XX гасыр башларына инде киселеп беткән. 1920 нче елларга чаклы Югары кырның Чәчәби тавына кадәрге өлеше безнең авыл биләмәләренә кергән.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы***

/Безнең спорт/



### Шахмат турнирында уңышлар

2 сентябрь көнне Казан шәһәренең Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге шахмат Федерациясе кысаларында Татарстан Республикасының 2024-2025 еллар өчен Гран При Кубогының беренче этабы узды. Яшь, ләкин шактый тәҗрибәле шахматчыбыз, VIII сыйныф укучысы Фаил Гафиятуллин әлеге турнирда 18 яшькәчә үенчылар арасында 2 нче урынга лаек булды. Киләчәктә дә уңышлар телибез сиңа, Фаил!

29 сентябрь көнне Аксубай районының җыелма шахмат командасы ел да Чаллы шәһәрендә узучы Татарстан Республикасы район һәм шәһәрләре арасында үткәрелүче шахмат турнирында катнашты. Безнең Фаил – район командасының төп уенчыларыннан берсе. Турнир ике көн дәвамында ике төр буенча үтте. Беренче көнне, рапид уен төрендә Фаил үз өстәлендә уйнаучы ир-атлар арасында беренче урынны яулады. Икенче көнне блиц уенында Аксубай җыелма командасы 2 нче урынга лаек булды. Фаилгә “Афәрин” диясе генә кала!

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Каусәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Тәхвәтуллин

# Мәктәп хәбәрчесе

**№7 (№58) сентябрь 2024 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

/Мөхәррир минбәре/

### Белем бәйрәме

Белем бәйрәме! Һәркем күңелендә бу көн чәчәк бәйләменнән торган, укытучыларны сагынып мәктәпкә барган көн буларак күз алдына килә. Белем кешенең йөзен нурлы иткәнлектәндер, бу көнне кояш та нурын кызганмый. Ул иртәдән үк күңел түрендә өметле ашкыну уята. Быелгы Белем көне 2 нче сентябрьдә елдагыча тантаналы төстә һәм үзенә генә хас күңелсезрәк тә бер дулкында узды. Чөнки быелгы бәйрәм түрендә тәүге тапкыр мәктәп бусагасын атлап керүче беренче сыйныф укучылары булмады.

Тантаналы бәйрәмне чыгарылышлар мәктәпкә, укытучыларга багышланган чыгышлары белән башлады. Тантаналы өлештә директор уку елы белән котлау сүзләрен җиткерде. Килгән кунакларга бер-бер артлы сүз бирелде. Район вәкиле Зәйнуллин Флүн Җәмил улы укучыларны котлап, илебез өчен кирәкле шәхесләр булып үсүләрен теләде. Җирле үзидарә җитәкчесе Хәснуллина Энҗе Мидхәт кызы да укучыларга тырышлык теләде. Бәйрәмгә килгән ветеран укытучылар балаларга үгет-нәсихәтләрен җиткереп, хәер-фатихаларын бирделәр. Ветеран укытучыбыз Исмагилов Рафик абый елдагыча үз иҗатыннан мәктәпкә, укучыларга багышланган шигырен укып узды.

Бәйрәмнең төп өлеше – чыгарылышларның бәйрәм түрендә шигырьләр сөйләве. Алар мәктәп турында шатлыклы мизгелләрне искә алып, укытучы хезмәтенә рәхмәтләр җиткереп чыгышларын тәмамладылар. Чара ахырында, гадәттәгечә, барлык укучылар өчен яңа уку елының беренче кыңгыравы чыңлады. Бу тавыш Белем бәйрәме киләсе елда алар өчен кайдадыр башка уку йортында дәвам итәчәген, аларның инде тиздән зур тормышка юл алачакларына ишарә итеп яңгырый.

Бәйрәм күңелле чәй табыны артында дәвам итте. Ветеран мөгаллимнәр, әти-әниләр, укытучылар өстәл артында җылы әңгәмә корып, бәйрәм истәлекләре белән уртаклаштылар. Лаеклы ялдагы хезмәттәшебез Замир абый үзенең үзенчәлекле тавышы белән җыр да сузгач, истәлекләр тагын яңарды. Ветеран мөгаллимнәр белән даими аралашу, бүгенге көн хезмәткәрләренә хезмәт дәрте өстәсә, укучыларда өлкәннәргә карата ихтирам тәрбияләү чарасы булып тора.

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***




### БӘЙРӘМ БҮГЕН!

Бүген иртән тордым да,
Хәйранга торам калып!
Чәчәк тотып агыла
Мәктәпкә таба халык!

Ах,ни булган?Ни булган?
Җәй узып киткән икән!
Балаларга "Уку елы",
Сентябрь килеп җиткән!

Уен,эш белән генә
Бармый икән дөньялар!
Балык тотып, уйнап туйгач.
Кирәк икән укулар!

Шатланышып, дуслар белән,
Мәктәпкә без йөребез!
Әти-әни исән булсын!
Тыныч булсын илебез!

Мәктәпләрдә белем алып.
Һөнәр алыйк без тизрәк.
Әти-әни, Туган илгә
Булыйк без яхшы терәк !

***Рафик Исмәгыйлев***
***ветеран укытучы***





/Котлыйбыз!/

Сентябрь аенда дөньяга килгән 7нче сыйныф укучысы Тәхфәтуллин Камилне чын күңелдән туган көне белән котлыйбыз. Дустыбызга саулык-сәламәтлек, укуында зур уңышларга ирешүен телибез.

Җитәкчебез Насыйров Рафик Гомәр улын 55 яшьлек юбилее белән котлап, ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, эшләрендә уңышлар теләп калабыз.



*/Котлыйбыз!/*

### *Тәрбиячеләр көне белән!*

27 сентябрь — тәрбиячеләр көне. Сабырлык үрнәгенә, йөрәкләрнең олысына ия була алган апалар көне. Самими сабыйларның күңелләрен күреп, теләкләрен тоеп, эшләренә тугры кала алганнар көне. Нәниләргә уеннар уйлап, беренче белемнәр бирә алган түземле мөгаллимәләр көне!

Без тәрбияче сүзенең төшенчәсен әллә никадәр санар идек. Шушы бәйрәмдә бакчабыз тәрбиячеләре Насыйрова Гөлүсә, Бәширова Альмира, Хәмидуллина Гөлүсә апаларның җаваплы хезмәтләрендә иҗат уңышлары теләп калабыз. Ныклы сәламәтлек, тыныч, имин көннәр насыйп булсын!

***"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе***

### *Сыйныфтан тыш чаралар*

*/Мәктәп тормышы/*



Быелгы уку елында да "Мөһим сөйләшүләр" ("Разговоры о важном") дәвам итәчәк. 5 нче сентябрьдә һөнәри юнәлеш бирү курсының 1нче дәресе узды. Бу курс һәр атнаның пәнҗешәмбесендә уздырылачак. Бу дәрестә укучылар төрле һөнәрләр белән танышачаклар.

3 нче сентябрьдә террорчылыкка каршы көрәштә теләктәшлек көнендә мәктәбебез "**Яшәү тамчысы**"дип аталган бөтенроссия акциясенә кушылды. Әлеге истәлекле дата 2004 нче елның Белем көнендә Төньяк Осетиянең Беслан шәһәре мәктәбендәге теракт белән бәйле. Әлеге җанөшеткеч фаҗигадә 300дән артык кешенең гомере өзелә, шуларның 186сы мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге сабый балалар."Яшәү тамчысы"чарасында уяулыкны югалтмау, җаваплылыкны киметмәү, икенче Беслан кабатланугa юл куймау, террорчылык белән көрәшергә генә түгел, аны кисәтүнең мөһимлеге турында искәртелде.

Шул ук көнне балалар кешелек тарихында алты еллык фаҗигадә – 1939 елның 1 сентябреннән 1945 елның 2 сентябренә кадәр дәвам иткән Икенче Бөтендөнья сугышы белән таныштылар. Чараның максаты булып балаларны рухи-әхлакый үстерү һәм тәрбияләү, Рәсәй гражданлык тәңгәллеген, патриотизм, Ватанга карата хөрмәт, Рәсәй дәүләт бәйрәмнәренә хөрмәт тәрбияләү иде.



Дөньяда ел саен 8 сентябрьдә **Халыкара белемлелек көне** билгеләп үтелә. Беренче мәртәбә ул мәгариф министрларының 1965 елның сентябрендә Иран дәүләте башкаласы Таһран шәһәрендә үткән наданлыкны бетерү буенча Бөтендөнья конференциясе инициативасы белән 1966 елда уздырыла. Бу көн аерым кеше өчен дә, тулаем җәмгыять өчен дә белем алуның һәм даими үсешнең мөһимлеген искә төшерә. Белемлелек – кешенең үзенә күрә «йөзе», аның җенесенә, яшенә һәм вазифасына карамастан,визит карточкасы. Белемле кешеләргә тормыш буйлап атлау җиңелрәк, алар алдында ишекләр ачыла, алар үзләренең теләкләрен тормышка ашыра һәм сәләтләрен үстерә алалар. Халыкара белемлелек көненә мәктәптә төрле чаралар уздырылды. Аларда белемле кешенең мөмкинлекләре күп булганлыгына мисаллар китерелде.

1962 елдан сентябрьнең һәр икенче якшәмбесен **Халыкара фашизм корбаннарын искә алу көне** карары кабул ителә. Аның төп максаты – фашизмны тергезү идеологиясе белән көрәш. 18 нче сентябрьдә дә балалар кешелек дөньсына куркыныч тудыручы **экстремистик, террористик актларга каршы көн**не билгеләп үттеләр. Укучылар тыныч тормышта яшәргә теләүләрен җиткерделәр.

20 нче сентябрьдә **"Мин яшәүне сайлыйм**" акциясе уздырылды. Шул ук көнне исерткеч эчемлекләргә каршы көн дә билгеләп үтелде. Бу ике чараны берләштереп "Күңелле стартлар" уздырылды. Вакытны кирәксез уйлардан арындырып, файдалы эшләргә юнәлдереп булганлыгы аңлатып үтелде. Спортка тартылу – сәламәтлеккә дә, баш мие эшчәнлегенә дә күп файда биргәне күптән билгеле.

***Олеся Пискарёва, тәрбия эшләре буенча киңәшче***

### *Көзге эшләр*

Мәктәптә һәрдаим ниндидер хезмәт чаралары булып тора. Гадәтенчә елына ике тапкыр мәктәп тирәсен җыештыру, бакчада эшләү кебек дәрестән тыш чаралар шундыйлардан. 21нче сентябрь көнне без мәктәптәге төрле эшләрне башкарырга диеп өмә оештырдык. Без, урты сыйныф укучылары, мәктәпнең кечкенә бакчасында бәрәңге алдык. Аларны ашханәгә һәм остаханәнең базларына җыеп, чистартып керттек. Ә кайбер балалар мәктәпнең кирәк-яракларын урнаштырдылар, тирә-ягын да җыештырдылар.

Тышта эшләгән көнне ашханәдәге ризыклар бигрәк тә тәмле булды. Мәктәп тирәсендә чиста булгач, күңелдә дә рәхәт булып калды. Тирә-ягыбызның чисталыгын бергәләшеп саклыйк!

***Ләйсән Закирова,VIIсыйныф укучысы***



*/Безнең сәяхәтләр/*

### *Сахрага чыктык*

Безнең гадәткә кергән, ямьле май ае һәм көзге алтын көннәрдә урманга сәяхәткә бара торган көннәребез бар. Менә Табигатьтә алтын көз. Елның әлеге фасылы – иң матур һәм могҗизалы вакыт! Агачлар алтын-сары төскә күмелгән, урманга көз-рәссам килгән, һәр яфракның үз төсе. Менә шуларны күреп, көзге матурлыкны күзәтеп, күңелләрне дә баетып кайту өчен, 27нче сентябрьдә Түбән Майнаның "Тукморза" дип аталган болынына юлга кузгалдык. Күбебез автобус һәм машиналарда, ә батыррак малайлар һәм кызлар велосипед белән бардык. Юл озын тоелса да тиз барып җиттек.

Без барып җиткәнче укытучы апа-абыйлар инде учак кабызып, казан аскан иделәр. Бер казанда уха пешерделәр. Балыкны укучылар үзләре тотып килде. Ә икенче казанда төрле җиләк-җимешләрдән бик тәмле компот кайнатылды.



Балалар бергәрәк җыелгач, Олеся апа төрле уеннар оештырды. Бераздан Рифкать абыйның умарталыгын да күреп килдек. Мондый матур, тыныч, күп төрле үләннәр үскән болында умарталарга эш җитәрлек. Биредән җыелган бал да шуңа күрә бик тәмледер, дип уйлап куйдым.

Волейбол уйнаганда апаларыбыз безне аш ашарга чакырдылар. Уха белән сыйлангач, кайбер кызлар гөлҗимеш җыярга китте. Башлангычлар төрле яфраклар да җыйдылар. Аяк астында төрле яфрак кыштырдавы гына ишетелә хәзер болында. Кошлар инде тынганнар. Андагы елга да кибеп беткәнлеген күреп кайттык. Безгә, күрше авыл балаларына, мондый сәяхәтләр тагын да мавыктыргычтыр. Күрше авылның да матур болыннарын күреп йөрибез. Мондый чаралар өчен укытучы апа һәм абыйларга рәхмәтемне белдерәм.

***Камил Тәхвәтуллин, VII сыйныф укучысы***



### *Нәниләребез сәяхәте*

Укучыларны төрле җирләргәалып бару –безнең мәктәп тормышында даими башкарыла торган эш. Ә менә балалар бакчасының нәниләрен әниләр белән берлектә каядыр алып бару беренче тапкыр булгандыр. Кечкенә балаларны ерак юлларга алып чыгу –зур җаваплылык та, батырлык та дип уйлыйм. Быелгы матур көз көнендә, тәрбиячеләр көненә туры китереп, балаларыбызны Казанга сәяхәткә алып чыгып киттек. Юлда да күңелле генә бардык. Иң беренче Казанның бик матур урыны "Әкият"курчак театры каршындагы паркта йөрдек. Анда әкият геройлары сыннарын карадык. Шуннан соң бинаның үзенә кереп, Нәкый Исәнбәтнең "Мырау батыр"әкиятен тамаша кылдык. Бу өлештән соң, шул ук бинадагы музейга кердек. Бер залда зур аквариумны сабыйларыбызга күрсәттек. Озак тормый балаларыбызны тәмле итеп ашатып, кайту юлына кузгалдык.

Бу кечкенә генә сәяхәтебез нәниләр өчен бик зур вакыйга булды. Бергәләшеп каядыр юл тоту – дуслыкка да нигез булыр дип ышанып калам. Әти-әниләр белән бердәм булып эшләгәндә генә эшебез нәтиҗәле булыр.

***Алсу Сафиуллина, әти-әниләр исеменнән***

*/Күңелле тәнәфес/*



1. Исемендә сан булган ашамлыклар әйтегез.
2. Саннар кергән нинди мәкальләр, әйтемнәр беләсез?
3. Исемендә сан булган нинди үсемлекләр беләсез?
4. Нинди сәгатьләр тәүлегенә ике генә тапкыр дөрес вакытны күрсәтә?
5. Имәндә 6 алма үсә иде. Берсен өзеп алдылар, ничә алма калды?
6.Биш 2 ледән 25 санын яса
7. Биш таякның ничә очы бар? Ә биш ярымның?
8. Кушу гамәлләрен генә кулланып, биш 2 ледән 28 санын яз.
9. 37 санын биш 3 ле ярдәмендә языгыз.
10. 24 санын нинди өч бертөрле цифр ярдәмендә язып була?
11. 100 санын биш бертөрле цифр ярдәмендә яз?
12. Бүлмәнең 4 почмагы бар, аның һәр почмагында мәче. Әгәр һәр мәчегә каршы тагын 3әр мәче утырса, бүлмәдә ничә мәче бар?